ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БИЕКТАУ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СУЫКСУ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
422729, Татарстан Республикасы, Биектау районы,
Суыксу авылы, Мәктәп ур., 9А

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
СУКСИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЫСОКОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
422729, Республика Татарстан, Высокогорский район,
с. Суксу, ул. Школьная, 9А

тел./факс 8(84365) 61-8-43, e-mail: Suks.Vsg@tatar.ru

КАРАР | ПОСТАНОВЛЕНИЕ

31 октябрь 2019 ел | № 38

**Агачларны һәм куаклыкларны кисүгә, ябалдашларын кыскартуга яки утыртуга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтү Административ регламентын раслау турында**

“Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында”, 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон, “Әйләнә-тирә мохитне саклау турында”, 2002 елның 10 гыйнварындагы 7-ФЗ номерлы Федераль законны тормышка ашыру максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “Татарстан Республикасының дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең админстратив регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларны үзгәрешләр кертү турында”, 2010 елның 2 ноябрендәге 880 номерлы карары белән эш йөртеп, Биектау муниципаль районы Суыксуавылы Уставы белән эш йөртеп, Суыксуавылы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Теркәлгән агачларны һәм куаклыкларны кисүгә, ябалдашларын кыскартуга яки утыртуга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтү административ регламентын расларга.
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникацияләр челтәрендә http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ веб-адресы буенча һәм “Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында” Интернет мәгълүмат-телекоммуникацияләр челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштырып халыкка җиткерергә.
3. Карар рәсми рәвештә бастырылып чыкканнан соң үз көченә керә.
4. Әлеге Карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Суыксуавыл җирлеге
Башкарма комитеты җитәкчесе Р.С.Низамиев

Кушымта

Расланган
Татарстан Республикасы
Биектау муниципаль районы
Суыксу авыл җирлеге
Башкарма комитеты карары белән
31.10.2019 № 38

# Агачларны һәм куаклыкларны кисүгә, ябалдашларын кыскартуга яки утыртуга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтү Административ регламенты

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Муниципаль хезмәт күрсәтүнең әлеге Административ регламенты (алга таба – Регламент) агачларны һәм куаклыкларны кисүгә, ябалдашларын кыскартуга һәм утыртуга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең стандартын һәм тәртибен билгели (алга таба – муниципаль хезмәт).

1.2. Муниципаль хезмәтне алучылар: физик һәм юридик затлар (алга таба гариза бирүче).

1.3. Муниципаль хезмәт Татарстан Республикасы Биектау районы Суыксуавыл җирлеге башкарма комитеты тарафыннан күрсәтелә (алга таба - Башкарма комитет).

1.3.1. Башкарма комитетның урнашкан урыны: 422729, Татарстан Республикасы, Биектау муниципаль районы, Суыксуавылы, Мәктәп урамы, 9А йорты.

Эш графигы:

дүшәмбе - җомга: 8.00 дән 17.00 гә кадәр

шимбә 8.00 дән 12.00 гә кадәр

якшәмбе – ял көннәре.

Ял һәм туклану өчен тәнәфес вакыты эчке хезмәт тәртибе кагыйдәләре белән билгеләнә.

Белешмәләр өчен телефон (884365) 61-8-43.

Керү шәхесне раслаучы документлар буенча.

1.3.2. “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә муниципаль районның рәсми сайты адресы (алга таба – “Интернет” челтәре): (http://vysokaya-gora.tatar.ru).

1.3.3. Муниципаль хезмәт күрсәтү турында мәгълүмат алынырга мөмкин:

1) Башкарма комитет биналарында урнашкан муниципаль хезмәтләр турында гариза бирүчеләр белән эшләү өчен мәгълүмати стендлар аша. Мәгълүмати стендларда урнашытырла торган мәгълүмат әлеге Регламентның 1.1, 1.3.2, 2.3, 2.5, 2.8, 2.10, 2.11, 5.1 пунктларында (пунктчаларында) булган муниципаль хезмәт күрсәтү турында мәгълүматны үз эченә ала.

2) “Интернет” челтәрендә муниципаль районның рәсми сайты аша (http:// www. vysokaya-gora.tatar.ru.);

3) Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр Порталында

(http://uslugi. tatar.ru/);

4) дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләр) бердәм порталында (http:/ www.gosuslugi.ru/);

5) Башкарма комитетта:

телдән мөрәҗәгать – шәхсән үзе яисә телефон аша;

язмача мөрәҗәгать (шул исәптән электрон документ формасында) – кәгазьдә почта аша, электрон формада электрон почта аша.

1.3.4. Муниципаль хезмәт күрсәтү сораулары буенча мәгълүматны башкарма комитет белгече тарафыннан муниципаль районның рәсми сайтына һәм Башкарма комитеты бинасындагы гариза бирүчеләр белән эшләү стендларына урнаштырыла.

1.4. Муниципаль хезмәт күрсәтү түбәндәгеләр нигезендә тормышка ашырыла:

Россия Федерациясе Җир кодексы, 2001 елның 25 октябрендәге 136-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – РФ ҖК)

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, 2004 елның 29 декабрендәге 190-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – РФ ШК);

Россия Федерациясе Урман кодексы, 2006 елның 4 декабрендәге 200-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – РФ УК);

“Әйләнә-тирә мохитне саклау турында”, 2002 елның 10 гыйнварындагы 7-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 7-ФЗ номерлы Федераль закон);

“Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында”, 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 131-ФЗ номерлы Федераль закон);

“Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында”, 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 210-ФЗ номерлы Федераль закон);

“Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында”, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (алга таба – 45-ТРЗ номерлы ТР Законы);

Биектау муниципаль районы Суыксуавыл җирлеге Советының 2015 елның 24 ноябрендәге 15 номерлы карары белән кабул ителгән “Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Суыксуавыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставы, 10.10.2016 № 53, 02.10.2017 № 80, 24.03.2018 №100, 13.09.2018 №124 кертелгән үзгәрешләр белән (алга таба -Устав);

Биектау муниципаль районы Суыксуавыл җирлеге Советының 2019 елның 29 июлендәге 161 номерлы карары белән расланган Биектау муниципаль районы Суыксуавыл җирлеге башкарма комитеты турында Нигезләмә (алга таба – Башкарма комитет турында Нигезләмә).

1.5. Әлеге Регламентта түбәндәге терминнар һәм билгеләмәләр кулланыла:

агачларны кисү – билгеле җирләрдә яки җир кишәрлекләрендә агач һәм куаклыкларның бер өлеше киселә торган агачлар кисү;

дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү күпфункцияле үзәгенең ерактагы эш урыны – Татарстан Республикасы муниципаль районының (шәһәр округының) шәһәр яки авыл җирлекләрендә оештырылган дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү күпфункцияле үзәгенең, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең “Дәүләт һәм

муниципаль хезмәтләр күрсәтү күпфункцияле үзәгенең эшчәнелеген оештыру Кагыйдәләрен раслау турында”, 2012 елның 22 декаберендәге 1376 номерлы карары белән расланган Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү күпфункцияле үзәгенең эшчәнелеген оештыру Кагыйдәләренең 34 пункты нигезендә,территориаль аерымланган структур бүлекчәсе (офисы);

техник хата – муниципаль хезмәт күрсәтүче орган тарафыннан җибәрелгән һәм документларга кертелгән мәгълүматлар (муниципаль хезмәт нәтиҗәсе) документтагы мәгълүмат нигезендә кертелгән мәгълүматларга туры килмәүгә китергән хата (ялгыш язу, басмадагы хата, грамматик яки арифметик хата яки шуның ише хата).

Әлеге Регламентта муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза (алга таба – гариза) астында муниципаль хезмәт күрсәтү турындагы сорату аңлашыла (27.07.2010, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 2 ст. 2 пункты). Гариза стандарт бланкта (1 нче кушымта) тутырыла.

## 2. Муниципаль хезмәт күрсәтү стандарты

| Муниципаль хезмәт күрсәтү стандартына таләпләр исемлеге | Стандартка таләпләр эчтәлеге | Хезмәт күрсәтүне яки таләпне билгеләүче норматив акт |
|---|---|---|
| 2.1. Муниципаль хезмәт күрсәтү исеме | Агачларны һәм куаклыкларны кисүгә, ябалдашларын кыскартуга һәм утыртуга рөхсәт бирү | РФ ШК;<br>РФ ҖК |
| 2.2. Турыдан-туры муниципаль хезмәт күрсәтүче җирле үзидарә башкарма-боеру органы исеме | Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Суыксуавыл җирлеге башкарма комитеты | Башкармк комитет турында Нигезләмә |
| 2.3. Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсенең тасвирламасы | Агачларны һәм куаклыкларны кисүгә, ябалдашларын кыскартуга һәм утыртуга рөхсәт (2 нче кушымта).<br>Агачларны һәм куаклыкларны кисүгә, ябалдашларын кыскартуга һәм утыртуга рөхсәт бирүдән баш тарту турында хәбәрнамә. | Тәртип |
| 2.4. Муниципаль хезмәт күрсәтү срогы, шул исәптән муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнашучы оешмаларга мөрәҗәгать итү зарурлыгын исәпкә алып, туктатылу мөмкинлеге Россия Федерациясе законнары белән каралган очракта муниципаль хезмәт күрсәтүне туктатып тору срогы | Агачларны һәм куаклыкларны кисүгә, ябалдашларын кыскартуга һәм утыртуга рөхсәт, гариза кергән көнне дә кертеп, 13 көн (1) эчендә бирелә. Муниципаль хезмәт күрсәтү срогы, административ процедураларны тормышка ашыру өчен минималь кирәкле суммадагы сроктан чыгып билгеләнгән. Административ процедураларның дәвамлылыгы эш көннәрендә исәпләнә.<br>Муниципаль хезмәт күрсәтү вакытын туктатып тору каралмаган. | Тәртип |
| 2.5. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен законнар һәм башка норматив хокукый актлар, шулай ук мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылырга тиешле муниципаль | 1) Гариза;<br>2) Шәхесне раслаучы документлар;<br>3) Вәкил вәкаләтләрен раслаучы документ (әгәр гариза бирүче исеменнән вәкил эшли икән);<br>4) Якындагы корылмаларга яки башка юнәлешләргә кадәр | Тәртип |

| | | |
|---|---|---|
| хезмәтләр күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләр, аларны алу ысуллары, шул исәптән электрон формада, аларны тапшыру тәртибе нигезендә кирәкле документларның тулы исемлеге | киселергә тиешле яшел үсентеләр төшерелгән җир кишәрлек схемасы;<br>5) Әгәр җир кишәрлеге күчемсез мөлкәтнең Бердәм дәүләт реестрында теркәлмәгән булса, җир кишәрлегенә хокук билгеләүче һәм раслый торган документларның таныкланган күчермәләре;<br>6) Биналар һәм корылмалар төзегәндә габаритларга эләгә торган яшел утыртмалар киселгән очракта, расланган проект документлары;<br>7) Агачларны кисү һәм аларны күчереп утырту шартларын территорияләренә кагылучы хуҗалар белән килештерү;<br>8) Үсентеләрне утыртканда яки күчереп утыртканда, инженерлык челтәрләре вәкилләре белән җир эшләрен үткәрүгә ордер ачу өчен килешү төзү.<br>Муниципаль хезмәт алу өчен гариза бланкын гариза бирүче Башкарма комитетта шәхси мөрәҗәгать иткәндә алырга мөмкин.<br>Бланкның электрон формасы Башкарма комитетның рәсми сайтында урнаштырылган.<br>Гариза һәм кушымта итеп бирелә торган документлар гариза бирүче тарафыннан кәгазьдә түбәндәге ысулларның берсе белән тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин: шәхсән үзе (гариза бирүче исеменнән ышаныч кәгазе нигезендә эшләүче зат); почта аша җибәрү.<br>Гариза һәм документлар шулай ук мөрәҗәгать итүче тарафыннан көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документ рәвешендә, гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләре аша, шул исәптән “Интернет” мәгълүмат- | |

| | | |
|---|---|---|
| | телекоммуникация челтәре һәм Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталы аша да тапшырылырга (җибәрелелергә) мөмкин. | |
| 2.6. Дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм мөрәҗәгать итүче тәкъдим итәргә хокуклы башка оешмалар карамагында булган һәм муниципаль хезмәт күрсәтү өчен норматив хокукый актлар нигезендә кирәкле документларның тулы исемлеге, шулай ук аларны алу ысуллары, шул исәптән электрон формада, аларны дәүләт органына, җирле үзидарә органына яисә әлеге документлар карамагында булган оешмаларга тапшыру тәртибе | Ведомствоара хезмәттәшлек кысаларында алына:<br>1) Күчемсез мөлкәтнең Бердәм дәүләт реестрыннан өземтә (күчемсез милек объектына теркәлгән хокуклар турында гомумалу мөмкинлеге булган мәгълүматларны үз эченә алган);<br>Гариза бирүче тәкъдим итәргә хокуклы документларны алу ысуллары һәм тапшыру тәртибе әлеге Регламентның 2.5 пункты белән билгеләнгән.<br>Дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм башка оешмалар карамагында булган югарыда саналган документларны гариза бирүчедән таләп итү тыела.<br>Югарыда күрсәтелгән мәгълүматларны үз эченә алган документларны гариза бирүче тапшырмаган очракта, бу гариза бирүчегә хезмәт күрсәтүдән баш тарту өчен нигез булып тормый. | |
| 2.7. Норматив хокукый актларда каралган очракларда муниципаль хезмәт күрсәтүче орган тарафыннан гамәлгә ашырыла торган хезмәт күрсәтү өчен килештерү таләп ителгән дәүләт хакимияте органнары (җирле үзидарә органнары) һәм аларның структур бүлекчәләре исемлеге | Килештерү таләп ителми. | |
| 2.8. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул | 1) Тиешле булмаган зат тарафыннан документлар тапшыру; | |

| | | |
|---|---|---|
| итүдән баш тарту өчен сәбәпләрнең тулы исемлеге | 2) Тапшырылган документларның әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документлар исемлегенә туры килмәве;<br>3) Гаризада һәм гаризага теркәлә торган документларда теркәлмәгән төзәтүләр, аларның эчтәлеген турыдан-туры аңлатырга мөмкинлек бирми торган җитди ялгышлыклар бар;<br>4) Документларны тиешле булмаган органга тапшыру | |
| 2.9. Муниципаль хезмәт күрсәтүне туктатып тору яки бирүдән баш тарту өчен сәбәпләрнең тулы исемлеге | Хезмәт күрсәтүне туктату өчен сәбәпләр каралмаган.<br>Баш тарту өчен сәбәпләр:<br>1) Гариза бирүче тарафыннан документлар тулы күләмдә тапшырылмаган яисә тапшырылган гаризада һәм (яки) документларда тулы булмаган һәм (яисә) дөрес булмаган мәгълүмат бар;<br>2) Тиешле документ гариза бирүче тарафыннан үз инициативасы буенча тапшырылмаган очракта, муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документ һәм (яки) мәгълүмат булмавы турында таныклаучы ведомствоара сорауга дәүләт хакимияте органының, җирле үзидарә органының яисә дәүләт хакимияте органы яки җирле үзидарә органына ведомство карамагындагы органына җавабы;<br>3) Күрше җир кишәрлекләреннән файдаланучылар арасында агачларны һәм куаклыклар кисү, ябалдашларын кыскарту һәм утырту мәсьәләсе буенча бәхәс булуы. | Тәртип |
| 2.10. Муниципаль хезмәт күрсәткән өчен алына торган дәүләт пошлинасы яки башка түләүне алу тәртибе, күләме һәм сәбәпләре | Муниципаль хезмәт түләүсез нигездә күрсәтелә. | |
| 2.11. Муниципаль хезмәт күрсәтү | Кирәкле һәм мәҗбүри хезмәт күрсәтү таләп ителми. | |

| | | |
|---|---|---|
| өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәт күрсәтүләр өчен түләү, шул исәптән мондый түләү күләмен исәпләү методикасы турында мәгълүматны да кертеп, алу тәртибе, күләме һәм сәбәпләре | | |
| 2.12. Муниципаль хезмәт күрсәтү турында сорау биргәндә һәм мондый хезмәт күрсәтү нәтиҗәләрен алганда чиратның максималь вакыты | Чират булганда муниципаль хезмәт алуга гариза бирү 15 минуттан да артмаска тиеш.<br>Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен алган очракта чиратта көтүнең максималь вакыты 15 минуттан артмаска тиеш | |
| 2.13. Гариза бирүченең муниципаль хезмәт күрсәтү турында соравын, шул исәптән электрон формада да, теркәү вакыты | Гариза кергән вакыттан бер көн эчендә. Ял (бәйрәм) көнендә электрон формада кергән сорау ялдан соң (бәйрәмнән) килүче эш көнендә теркәлә. | |
| 2.14. Муниципаль хезмәт күрсәтелә торган биналарга, гариза бирүчеләргәкөтү һәм кабул итү урынына, шул исәптән инвалидларны социаль яклау турындагы Россия Федерациясе законнары нигезендә әлеге объектларның инвалидлар өчен тоткарсызлыкны да тәэмин итеп, мондый хезмәтләр күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы һәм мультимедияле мәгълүмат урнаштыру һәм рәсмиләштерүгә | Муниципаль хезмәт күрсәтү янгын системасы һәм янгын сүндерү системасы белән җиһазландырылган, документларны рәсмиләштерү өчен кирәкле җиһазлар, мәгълүмати стендлар булган биналарда башкарыла.<br>Инвалидларның муниципаль хезмәт күрсәтү урынына тоткарлыксыз керү мөмкинлеге тәэмин ителә (бинага уңайлы керү- чыгу һәм аның эчендә хәрәкәт итү).<br>Муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы һәм мультимедиа мәгълүматы гариза бирүчеләр өчен, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып, уңайлы урыннарда урнаштырыла | |

| | | |
|---|---|---|
| таләпләр | | |
| 2.15. Муниципаль хезмәт күрсәтүнең һәркем өчен мөмкинлеге һәм сыйфатлы булу күрсәткечләре, шул исәптән мөрәҗәгать итүченең вазыйфаи затлар белән үзара хезмәттәшлеге һәм аларның дәвамлылыгы, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәгендә муниципаль хезмәт алу мөмкинлеге, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәгенең эш урыннарында, муниципаль хезмәт күрсәтүнең барышы турында, шул исәптән мәгълүмати-коммуникацион технологияләр куллану белән дә, мәгълүмат алу мөмкинлеге | Муниципаль хезмәт күрсәтүнең һәркем өчен ала алу мөмкинлеге күрсәткечләре булып түбәндәгеләр тора: Башкарма комитет бинасының җәмәгать транспортыннан файдалану мөмкинлеге зонасында урнашуы; кирәкле сандагы белгечләр, шулай ук гариза бирүчеләрдән документларны кабул итә торган биналар булуы; мәгълүмат ресурсларында “Интернет” челтәрендә (http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/), мәгълүмати стендларда, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең Бердәм порталында муниципаль хезмәт күрсәтү ысуллары, тәртибе һәм сроклары турында тулы мәгълүмат булуы; инвалидларга башка затлар белән беррәттән хезмәт күрсәтүгә комачаулаучы киртәләрне җиңеп чыгарга ярдәм.<br>Муниципаль хезмәт күрсәтүнең сыйфаты түбәндәгеләр белән характерлана: гариза бирүчеләргә документлар кабул итү һәм бирү чиратлары юклыгы; муниципаль хезмәт күрсәтү срокларын бозулар булмавы; муниципаль хезмәт күрсәтүче муниципаль хезмәткәрләрнең гамәлләренә (гамәл кылмауларына) карата шикаять булмавы; муниципаль хезмәт күрсәтүче муниципаль хезмәткәрләрнең гариза бирүчеләргә карата әдәпсез, игътибарсыз мөнәсәбәтенә карата шикаятьләр булмавы.<br>Муниципаль хезмәт күрсәтү турында сорау биргәндә һәм муниципаль хезмәт нәтиҗәсе алган очракта муниципаль хезмәт күрсәтүче вазыйфаи затның һәм гариза бирүченең бер тапкыр үзара хезмәттәшлеге күздә тотыла.<br>Хезмәттәшлекнең озынлыгы регламент белән билгеләнә. Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең | |

| | | |
|---|---|---|
| | күпфункцияле үзәгендә (алга таба – КФҮ) муниципаль хезмәт күрсәткәндә, КФҮнең читтә урнашкан эш урыннарында консультация бирүне, документлар кабул итүне һәм бирүне КФҮ белгече башкара. Мөрәҗәгать итүче тарафыннан муниципаль хезмәт күрсәтүнең барышы турында мәгълүмат сайттан (http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/.), дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең Бердәм порталыннан, КФҮләрдән алына ала. | |
| 2.16. Электрон формада муниципаль хезмәт күрсәтү үзенчәлекләре | Муниципаль хезмәтләрне электрон формада алу тәртибе турында консультацияне Интернет-кабул итү аша яисә Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр Порталы аша алырга мөмкин.<br>Әгәр закон нигезендә муниципаль хезмәт күрсәтү турында гаризаны электрон формада бирү каралган булса, гариза Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр Порталы (http://uslugi. tatar.ru/) яки дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) Бердәм порталы (http:/ www.gosuslugi.ru/) аша бирелә. | |

## 3. Административ процедураларның составы, эзлеклелеге һәм үтәү сроклары, аларны үтәү тәртибенә карата таләпләр, шул исәптән электрон формада административ процедураларны башкару үзенчәлекләре, шулай ук дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләрендә, күпфункцияле үзәгенең ерак урнашкан эш урыннарында административ процедураларны башкару үзенчәлекләре

3.1. Муниципаль хезмәт күрсәткәндә гамәлләр тәртибен тасвирламасы

3.1.1. Муниципаль хезмәт күрсәтү түбәндәге процедураларны үз эченә ала:

1) гариза бирүчегә консультация бирү;

2) гаризаны кабул итү һәм теркәү;

3) муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнашучы органнарга ведомствоара соратулар формалаштыру һәм җибәрү;

4) комиссия актын төзү;

5) муниципаль хезмәт нәтиҗәләрен әзерләү;

6) гариза бирүчегә муниципаль хезмәт нәтиҗәсен бирү.

3.2. Гариза бирүчеләргә консультацияләр бирү

3.2.1. Гариза бирүче муниципаль хезмәт алу тәртибе турында консультация алу өчен Башкарма комитетка шәхсән үзләре һәм (яки) телефон аша мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

Башкарма комитет белгече гариза бирүчегә консультация бирә, шул исәптән муниципаль хезмәт алу өчен кирәкле документларның составы, формасы һәм эчтәлеге буенча һәм кирәк булганда гариза бланкын тутыруда ярдәм күрсәтә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура мөрәҗәгать итү көнендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: тәкъдим ителгән документларның составы, формасы һәм эчтәлеге буенча консультацияләр.

3.3. Гариза кабул итү һәм теркәү

3.3.1. Гариза бирүче шәхсән үзе, ышанычлы зат яки КФҮ, КФҮнең еракта урнашкан эш урыны аша муниципаль хезмәт күрсәтү турында язма гариза тапшыра һәм әлеге Регламентның 2.5 пункты нигезендә документларны Башкарма комитетка тапшыра.

Муниципаль хезмәт күрсәтү турындагы гариза электрон формада Башкарма комитетка электрон почта яки Интернет-кабул итү аша җибәрелә. Электрон формада килгән гаризаны теркәү билгеләнгән тәртиптә башкарыла.

3.3.2. Гаризалар кабул итүне алып баручы Башкарма комитет белгече түбәндәгеләрне гамәлгә ашыра:

гариза бирүченең шәхесен билгели;

гариза бирүченең вәкаләтләрен тикшерә (ышаныч кәгазе буенча эш иткәндә);

әлеге Регламентның 2.5 пунктында каралган документларның булу-булмавын тикшерә;

тәкъдим ителгән документларның билгеләнгән таләпләргә (документларның күчермәләрен тиешенчә рәсмиләштерү, документларда буяган урыннар, өстәмә язулар, сызылган сүзләр һәм башка тиешле төзәтүләр булмау) туры килүен тикшерә.

Кимчелекләр булмаган очракта Башкарма комитет белгече түбәндәгеләрне гамәлгә ашыра:

гаризаны кабул итү һәм махсус журналда теркәү;

кабул итү датасы, хезмәт күрсәтүне үтәү датасы һәм вакыты турында тамга белән гариза бирүчегә тапшырылган документларның күчермәләрен бирү;

гаризаны тикшерү өчен Башкарма комитет җитәкчесенә карап җибәрү.

Документларны кабул итүдән баш тарту өчен сәбәп булган очракта, документларны кабул итүне алып баручы Башкарма комитет белгече, гариза бирүчегә гаризаны теркәү өчен каршылыклар булуы турында хәбәр итә һәм документларны кабул итүдән баш тарту өчен ачыкланган сәбәпләрнең эчтәлеген язмача аңлату белән документлар кире кайтара.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар түбәндәгечә гамәлгә ашырыла:

гаризалар һәм документлар кабул итү 15 минут эчендә;

гаризаны гариза кергән вакыттан бер көн эчендә теркәү.

Процедураларның нәтиҗәсе: Башкарма комитет җитәкчесенә тикшерергә юнәлдерелгән кабул ителгән һәм теркәлгән гариза яки гариза бирүчегә кире кайтарылган документлар.

3.4. Муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнашучы органнарга ведомствоара соратулар формалаштыру һәм җибәрү

3.4.1. Башкарма комитет белгече электрон формада ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы аша күчемсез мөлкәткә һәм аның белән алыш-бирешләргә хокукларның Бердәм дәүләт реестрыннан өземтә (күчемсез милек объектына теркәлгән хокуклар турында һәркем ала алырлык мәгълүматлар булган) тәкъдим итү турында сорату җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза кергән вакыттан алып бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: җибәрелгән сорату.

3.4.2. Ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы аша кергән мәгълүмат белән тәэмин итүчеләр белгечләре соратып алына торган документлар (мәгълүмат) тапшыралар яисә муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документ һәм (яки) мәгълүмат булмавы турында хәбәрнамәләр җибәрәләр (алга таба – баш тарту турында хәбәрнамә).

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар документ һәм мәгълүмат бирә торган органга яки оешмага ведомствоара сорату кергән көннән алып өч көн эчендә тормышка ашырылалар.

Процедураларның нәтиҗәсе: Башкарма комитетка җибәрелгән документлар (мәгълүматлар) яисә баш тарту турында хәбәрнамә.

3.5. Комиссия актын төзү

3.5.1. Башкарма комитет белгече тормышка ашыра:
тапшырылган документларда булган мәгълүматларның дөреслеген тикшерү;
хисап эшләрен рәсмиләштерү (барлык документларны аерым папкага туплау);
хисап эшен комиссия каралуына акт төзү өчен җибәрү.
Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар соратуларга җаваплар кергән вакыттан алып бер көн эчендә гамәлгә ашырыла.
Процедураларның нәтиҗәсе: комиссиягә юнәлдерелгән исәпкә алу эше.
3.5.2. Башкарма комитет җитәкчесе тормышка ашыра:
кабул ителгән документларны өйрәнү;
киселергә, ябалдашларын кыскартырга тиешле агачлар һәм куаклыклар урнашкан урынны карау яки утырту урынын карау датасын билгели;
комиссия әгъзаларына комиссия утырышы көне турында хәбәр итү.
Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар документлар кергән вакыттан алып ике көн эчендә гамәлгә ашырыла.
Процедураларның нәтиҗәсе: комиссия әгъзаларына утырыш көне турында хәбәр итү.
3.5.3. Билгеләнгән көндә комиссия урынга чыга гариза бирүче катнашында киселергә тиешле агачларны карауны тормышка ашыра. Тикшерү нәтиҗәләре буенча тикшерү акты төзелә (3 нче кушымта).
Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар карау көнендә гамәлгә ашырыла.
Процедураларның нәтиҗәсе: тикшерү акты.

3.6. Муниципаль хезмәтнең нәтиҗәләрен әзерләү
3.6.1. Комиссия тәкъдим иткән тикшерү акты нигезендә авыл җирлеге Башкарма комитеты белгече агачларны кисүгә рөхсәт проектын (алга таба – рөхсәт) яки муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында белдерү проектын әзерли (алга таба – хәбәрнамә) һәм Башкарма комитет җитәкчесенә килештерүгә җибәрә.
Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура тикшерү акты кергән вакыттан алып ике көн эчендә гамәлгә ашырыла.
Процедураның нәтиҗәсе: имзалауга юнәлтелгән рөхсәт проекты (хәбәрнамә).
3.6.2. Башкарма комитет җитәкчесе карарны (хәбәрнамәне) имзалый һәм гариза бирүчегә бирү өчен башкарма комитет белгеченә җибәрә.
Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура алдагы процедураны тәмамлаганнан соң бер көн эчендә гамәлгә ашырыла.
Процедураның нәтиҗәсе: башкарма комитет җитәкчесе урынбасарына җибәрелгән кул куелган рөхсәт (хәбәрнамә).

3.7. Гариза бирүчегә муниципаль хезмәт нәтиҗәсе бирү
3.7.1. Башкарма комитет белгече рөхсәтне (хәбәрнамәне) терки һәм гариза бирүчегә бирә яки почта аша җибәрә.
Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар түбәндәгечә гамәлгә ашырыла:
гариза бирүче шәхсән үзе килгән очракта - 15 минут эчендә;

җавап почта аша җибәрелгән очракта алдагы процедуралар тәмамланганнан соң бер көн эчендә.

Процедураның нәтиҗәсе: бирелгән (җибәрелгән) хәбәрнамә.

3.8. КФҮ аша муниципаль хезмәт күрсәтү

3.8.1. Гариза бирүче КФҮләрдә муниципаль хезмәт алу өчен, КФҮнең еракта урнашкан эш урынына мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

3.8.2. КФҮ аша муниципаль хезмәт күрсәтү КФҮ эше регламенты нигезендә билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.

3.8.3. КФҮтән муниципаль хезмәт алуга документлар кергәндә процедуралар әлеге Регламентның 3.3 – 3.6 пунктлары нигезендә гамәлгә ашырыла. Муниципаль хезмәт нәтиҗәсе КФҮкә җибәрелә.

3.9. Техник хаталарны төзәтү.

3.9.1. Муниципаль хезмәт нәтиҗәсе булып торган документта техник хаталар ачыкланган очракта, гариза бирүче Башкарма комитетка тапшыра:

техник хаталарны төзәтү турында гариза (4 нче кушымта);

гариза бирүчегә техник хата булган муниципаль хезмәт нәтиҗәсе буларак бирелгән документ;

техник хаталар булуны раслаучы юридик көчкә ия документлар.

Документта күрсәтелгән белешмәләрдә техник хаталарны төзәтү турында гариза гариза бирүче шәхсән үзе (вәкаләтле вәкил) тарафыннан, яисә почта аша (шул исәптән электрон почта аша), яки дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең Бердәм порталы яисә күпфункцияле үзәк аша бирелә.

3.9.2. Документлар кабул итү өчен җаваплы Башкарма комитет белгече техник хаталарны төзәтү турында гариза кабул итә, теркәлгән документлар белән гариза яза һәм аларны Баәшкарма комитет җитәкчесенә тапшыра.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура гариза теркәлгәннән соң бер көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: Башкарма комитет җитәкчесенә тикшерүгә җибәрелгән кабул ителгән һәм теркәлгән гариза.

3.9.3. Башкарма комитет җитәкчесе документларны карый һәм хезмәт нәтиҗәсе булган документка төзәтмәләрне кертү максатларында әлеге Регламентның 3.6 пунктында каралган процедураларны гамәлгә ашыра һәм гариза бирүчедән (вәкаләтле вәкилдән) шәхсән кул куйдырып, гариза бирүчедән (вәкаләтле вәкилдән) техник хатасы булган документның төп нөсхәсен алып төзәтелгәнен бирә яисә гариза бирүчегә почта аша (электрон почта аша) техник хатасы булган документның төп нөсхәсен алып Башкарма комитеттан төзәтелгән документ тапшыру мөмкинлеге турында хат җибәрә (электрон почта аша).

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура техник хаталар ачыкланганнан яки теләсә кайсы кызыксынган заттан җибәрелгән хата турында гариза алганнан соң өч көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: гариза бирүчегә бирелгән (җибәрелгән) документ.

4. Муниципаль хезмәт күрсәтүне контрольдә тоту тәртибе һәм формалары

4.1. Муниципаль хезмәт күрсәтүнең тулылыгын һәм сыйфатын контрольдә тоту, гариза бирүчеләрнең хокукларын бозу очракларын ачыклау һәм бетерү, муниципаль хезмәт күрсәтү процедураларының үтәлешен тикшерү, җирле үзидарә органы вазыйфаи затларының гамәлләренә (гамәл кылмауларына) карарлар әзерләүне үз эченә ала.

Административ процедураларның үтәлешен контрольдә тоту формалары

1) муниципаль хезмәт күрсәтү буенча документлар проектларын тикшерү һәм килештерү. Тикшерү нәтиҗәсе булып проектларны визалау тора;

2) башкарыла торган делопроизводствоның билгеләнгән тәртиптә башкарылуын тикшерү

3) муниципаль хезмәт күрсәтү процедураларының үтәлешен билгеләнгән тәртиптә тикшереп тору.

Контроль тикшерүләр план нигезендә (җирле үзидарә органы эшчәнлегенең ярты еллык яки еллык планнары нигезендә гамәлгә ашырыла) һәм планнан тыш булырга мөмкин. Тикшерүләр уздырганда муниципаль хезмәт күрсәтү (комплекслы тикшерүләр) белән бәйле барлык мәсьәләләр яисә гариза бирүченең конкрет мөрәҗәгате буенча да карала ала.

Муниципаль хезмәт күрсәтүгә контрольне гамәлгә ашыру һәм карарлар кабул итү максатларында Башкарма комитет җитәкчесенә муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре турында белешмәләр тапшырыла.

4.2. Муниципаль хезмәт күрсәтү буенча административ процедураларда билгеләнгән гамәлләр үтәлешен агымдагы контрольдә тоту, муниципаль хезмәт күрсәтү буенча эшләрне оештыру өчен җаваплы Башкарма комитет җитәкчесе тарафыннан башкарыла.

4.3. Агымдагы контрольне гамәлгә ашыручы вазыйфаи затлар исемлеге җирле үзидарә органының структур бүлекчәләре һәм вазыйфаи регламентлар турында нигезләмәләр белән билгеләнә.

Үткәрелгән тикшерүләр нәтиҗәләре буенча гариза бирүчеләрнең хокукларын бозу очраклары ачыкланган очракта, гаепле затлар Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплылыкка тартыла.

4.4. Җирле үзидарә органы җитәкчесе гариза бирүчеләрнең мөрәҗәгатьләрен вакытында карап тикшермәгән өчен җаваплылык тота.

Башкарма комитет җитәкчесе урынбасары әлеге Регламентның 3 бүлегендә күрсәтелгән административ гамәлләрнең вакытында һәм (яки) тиешенчә башкарылмавы өчен җавап бирә.

Муниципаль хезмәт күрсәтү барышында кабул ителә торган (гамәлгә ашырыла торган) карарлар һәм гамәлләр (гамәл кылмау) өчен вазыйфаи затлар һәм башка муниципаль хезмәткәрләр законда билгеләнгән тәртиптә җаваплы.

4.5. Муниципаль хезмәт күрсәтүне гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалары тарафыннан контрольдә тоту муниципаль хезмәт күрсәткәндә авыл җирлеге органы эшчәнлегенең ачыклыгы, муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе турында тулы, актуаль һәм ышанычлы мәгълүмат алу һәм муниципаль хезмәт

күрсәтү процессында мөрәҗәгатьләрне (шикаятьләрне) судка кадәр карап тикшерү мөмкинлеге аша гамәлгә ашырыла.

5. Муниципаль хезмәт күрсәтүче органнарның, шулай ук аларның вазыйфаи затларының, муниципаль хезмәткәрләрнең гамәлләренә (гамәл кылмауларына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү тәртибе

5.1. Муниципаль хезмәт алучылар муниципаль хезмәт тәкъдим итүдә катнашучы Башкарма комитет хезмәткәрләренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) судка кадәр шикаять белән Башкарма комитетка яки муниципаль берәмлек Советына шикаять белән мөрәҗәгать итәргә хокуклы. Күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять закон белән билгеләнгән тәртиптә шикаять ителә.

Гариза бирүче шикаять белән шул исәптән түбәндәге очракларда да мөрәҗәгать итә ала:

1) 210-ФЗ Федераль законның 15.1 статьясында күрсәтелгән сорату, муниципаль хезмәт күрсәтү турында соратуның теркәү срогын бозу;

2) муниципаль хезмәт күрсәтү турында сорату теркәүнең срогын бозу. Күрсәтелгән очракта, күпфункцияле үзәк, күпфункцияле үзәк хезмәткәре гамәлләренә (гамәл кылмауларына) гариза бирүче тарафыннан судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү  гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять белдерелә торган күпфункцияле үзәккә билгеле дәүләт яки муниципаль хезмәтне тулы итеп, 2010 ел, 27 нче июль 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 нчы статьясы 1.3 бүлеге белән билгеләнгән тәртиптә күрсәтү буенча функция йөкләнгән очракта гына мөмкин;

3) гариза бирүчедән муниципаль хезмәт күрсәтү өчен Россия Федерацисе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларында  каралмаган өстәмә документлар яки мәгълүмат яисә эшчәнлек таләп итү;

4) гариза бирүчедән муниципаль хезмәт күрсәтү өчен Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларда  күздә тотылган документларны кабул итүне кире кагу;

5) федераль законнар, федераль законнар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең башка төр норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы законнары һәм башка төр норматив хокукый актлары, муниципаль хокукый актларында  кире кагу өчен җирлек булмаган очракта муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту. Күрсәтелгән очракта, күпфункцияле үзәк, күпфункцияле үзәк хезмәткәре гамәлләренә (гамәл кылмауларына) гариза бирүче тарафыннан судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү  гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять белдерелә торган  күпфункцияле үзәккә билгеле муниципаль хезмәтне тулы итеп 2010 ел, 27 нче июль 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 нчы статьясы 1.3 бүлеге белән билгеләнгән тәртиптә күрсәтү буенча функция йөкләнгән очракта гына мөмкин;

6) гариза бирүчедән муниципаль хезмәт күрсәткән очракта Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары, муниципаль хокукый актларында каралмаган түләү таләп итү;

7) муниципаль хезмәт күрсәтүче органның, муниципаль хезмәт күрсәтүче органның вазыйфаи затының, күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясы 1 бүлегендә күздә тотылган оешмаларның, яки аларның хезмәткәрләренең муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсендә документларда алар җибәргән хәреф хаталарын һәм хаталарны төзәтүдән баш тарту, яисә андый төзәтмәләрнең билгеләнгән срогын бозган очракта. Күрсәтелгән очракта гариза бирүче тарафыннан күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять белдерелгән күпфункцияле үзәккә 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясы 1.3 бүлегендә билгеләнгән тәртиптә тиешле дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтү тулы күләмдә һәм тәртиптә булган очракта гына мөмкин;

8) муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре буенча документлар бирүнең срогын һәм тәртибен бозу;

9) муниципаль хезмәт күрсәтүне туктатып тору, әгәр дә федераль законнар, алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең башка төр норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы законнары һәм башка төр норматив хокукый актлары, муниципаль хокукый актларында моның өчен нигез булмаса. Күрсәтелгән очракта гариза бирүче тарафыннан күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять белдерелгән күпфункцияле үзәккә 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясы 1.3 бүлегендә билгеләнгән тәртиптә тиешле дәүләт хезмәтләре күрсәтү тулы күләмдә һәм тәртиптә булган очракта гына мөмкин;

10) муниципаль хезмәт күрсәткәндә гариза бирүчедән беренче тапкыр муниципаль хезмәт күрсәткән вакытта кирәкле булган документларны кире какканда аларның юклыгы һәм (яки) тулы булмаганлыгы күрсәтелмәгән документларны яки мәгълүматларны таләп итү, яисә 210-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясы 1 бүлеге 4 пунктында каралган очраклардан кала муниципаль хезмәтне күрсәтү. Күрсәтелгән очракта гариза бирүче тарафыннан күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять белдерелгән күпфункцияле үзәккә 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясы 1.3 бүлегендә билгеләнгән тәртиптә тиешле муниципаль хезмәт күрсәтү тулы күләмдә һәм тәртиптә булган очракта гына мөмкин.

5.2. Муниципаль хезмәт күрсәтүче органның, муниципаль хезмәт күрсәтүче органның вазыйфаи затының, муниципаль хезмәткәрнең, муниципаль хезмәт күрсәтүче орган җитәкчесенең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять почта, күпфункцияле үзәк, “Интернет” мәгълүмати-телекоммуникацияләр

челтәре, Биектау муниципаль районы рәсми сайты (http://vysokaya-gora.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы (http://uslugi.tatar.ru), Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталы (http://www.gosuslugi.ru), шулай ук гариза бирүчене шәхсән кабул иткәндә кабул ителергә мөмкин. Күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү почта, "Интернет" мәгълүмати-телекоммуникацияләр челтәре аркылы, күпфункцияле үзәкнең рәсми сайты, Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы яисә төбәк дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша, шулай ук гариза бирүчене шәхсән кабул иткәндә кабул ителергә мөмкин. 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясы "г" бүлегендә каралган оешмалар һәм шулай ук аларның хезмәткәрләре карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять белдерү почта, "Интернет" мәгълүмати-телекоммуникацияләр челтәре, әлеге оешмаларның рәсми сайтлары, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы, Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы (функцияләр), шулай ук гариза бирүчене шәхсән кабул иткәндә кабул ителергә мөмкин.

5.3. Дәүләт хезмәте күрсәтүче, муниципаль хезмәт күрсәтүче органга, күп функцияле үзәк, күп функцияле үзәк учредителенә, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясы 1.1 бүлегендә каралган оешмаларга, яисә югары органга (алар булган очракта) кергән шикаять аны теркәгән көннән алып унбиш эш көне эчендә карап тикшерелергә тиеш, ә дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, муниципаль хезмәт күрсәтүче органның, күп функцияле үзәкнең, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясы 1.1 бүлегендә каралган оешмаларның гариза бирүчедән документлар кабул итүдән баш тартуы яисә җибәрелгән төгәлсезлекләрне һәм хаталарны төзәтүдә яисә төзәтүләрнең билгеләнгән срогын бозу турында шикаять бирү очрагында, теркәлгән көннән соң биш эш көне эчендә карап тикшерелергә тиеш.

5.4. Шикаять үз эченә түбәндәге мәгълүматны алырга тиеш:

1) карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять бирелә торган дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, муниципаль хезмәт күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның яисә муниципаль хезмәт күрсәтүче органның вазыйфаи затының, яисә дәүләт яки муниципаль хезмәткәрнең, күп функцияле үзәкнең, аның җитәкчесенең һәм (яки) хезмәткәренең, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясы 1.1 бүлегендә каралган оешмаларның, аларның җитәкчеләренең һәм (яки) хезмәткәрләренең исемнәре;

2) гариза бирүчегә җавап бирү өчен фамилиясе, исеме, әтисенең исеме (соңгысы булган очракта), гариза бирүченең яшәү урыны турында белешмә – физик затның яисә исеме, гариза бирүче юридик затның урнашкан урыны турында белешмә, хәбәрләшү өчен телефон номеры, электрон почта адресы (адреслары) (ахыргысы булган очракта) һәм почта адресы;

3) карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять белдерелүче дәүләт хезмәте күрсәтү орган, муниципаль хезмәт күрсәтүче орган, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның яисә муниципаль хезмәт күрсәтүче органның вазыйфаи заты,

яисә дәүләт яки муниципаль хезмәткәрнең, күпфункцияле үзәк, күпфункцияле үзәк хезмәткәре, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясы 1.1 бүлегендә каралган оешмалар, аларның хезмәткәрләре турында мәгълүматлар;

4) гариза бирүче дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, муниципаль хезмәт күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның яисә муниципаль хезмәт күрсәтүче органның вазыйфаи затының, яисә дәүләт яки муниципаль хезмәткәрнең, күп функцияле үзәкнең, күп функцияле үзәк хезмәткәренең, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясы 1.1 бүлегендә каралган оешмаларның, аларның хезмәткәрләренең карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмаулары) белән килешмәве нигезендә торган дәлилләр. Гариза бирүче тарафыннан гариза бирүченең дәлилләрен раслый торган документлар (алар булган очракта), яисә аларның күчермәләре тәкъдим ителергә мөмкин.

5.5. Шикаятькә шикаятьтә бәян ителгән хәлләрне раслаучы документлар һәм аларның күчермәләре беркетелергә мөмкин. Әлеге очракта шикаятьтә аңа беркетелгән документлар исемлеге китерелә.

5.6. Шикаять аны тәкъдим иткән муниципаль хезмәтне алучы тарафыннан имзалана.

5.7. Шикаятьне карау нәтиҗәләре буенча, түбәндәге карарларның берсе кабул ителә:

1) шикаять канәгатьләндерелә, шул исәптән кабул ителгән карарны кире кагу формасында, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән гаризаны кертү вакытында җибәрелгән хәреф хаталарын һәм хаталарны төзәтү буенча төзәтмәләрне, гариза бирүчегә акчалата чараларны кире кайтару, ләкин акча алу Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары, муниципаль хокукый актлар нигезендә каралмаган;

2) шикаять канәгатьләндерелүдән баш тартыла.

Әлеге пунктта күрсәтелгән карар кабул ителгәннең икенче көннән үк соңга калмыйча, гариза бирүчегә язма рәвештә, теләге булган очракта электрон рәвештә шикаятьне карау нәтиҗәләре күрсәтелгән дәлилләнгән җавап хаты җибәрелә.

5.8. Шикаять канәгатьләндерелергә тиеш дип танылган очракта гариза бирүчегә җибәрелә торган җавапта муниципаль хезмәт күрсәтү вакытында ачыкланган кагыйдә бозулар кичекмәстән юкка чыгару өчен дәүләт хезмәте күрсәтү органының, күпфункцияле үзәкнең, яки 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясы 1 бүлегендә каралган оешмаларның эшчәнлекләре турында мәгълүмат бирелә, шулай ук гариза бирүчедән китерелгән уңайсызлыклар өчен гафу сорала һәм киләчәктә муниципаль хезмәт алу максатларында гариза бирүче эшләргә тиешле эшчәнлек турында мәгълүмат күрсәтелә.

5.9. Шикаять канәгатьләндерелергә тиеш түгел дип танылган очракта, кабул ителгән карарның сәбәпләрен аңлатып нигезле аңлатмалар, шулай ук кабул ителгән карарны шикаять итү тәртибе турында мәгълүмат бирелә.

5.10. Карарны кабул итү барышында яки шикаятьне карау нәтиҗәләре буенча административ хокук бозулар яки вазыйфаи зат тарафыннан хокук бозу очраклары булу мөмкинлеге ачыкланса, шикаятьятләрне карау буенча вәкаләтләргә ия булган хезмәткәр барлык материалларны прокуратура органнарына җибәрелә.

1 нче кушымта
Агачларны һәм куаклыкларны кисүгә,
ябалдашларын кыскартуга яки
утыртуга рөхсәт бирү буенча
муниципаль хезмәт күрсәтү
Административ регламентына

_______________________________________
(муниципаль берәмлекнең

_______________________________________
җирле үзидарә органы исеме )

_______________________________________нан

_______________________________________
(алга таба-гариза бирүче).
(юридик затларга - тулы исеме,
оештыру-хокукый форма, дәүләт
теркәве турында мәгълүматлар; физик
затларга - фамилиясе, исеме, әтисенең исеме,
паспорт мәгълүматлары, телефон)

Агачларны һәм куаклыкларны кисүгә, ябалдашларын кыскартуга яки
утыртуга рөхсәт бирү турында
ГАРИЗА

Агачларның милек хокукында булган бинаның нигезенә якын булуы сәбәпле түбәндәге адрес буенча: _______________________________________ _ ___________ данә күләмендә агачларны кисүне (ябалдашларын кыскартуны) килештерүегезне сорыйм. Нигезне җимерәләр. Агачлар бик карт, көчле җилдә ботаклар җиргә сынып төшә. Эшләрне үткәргәннән соң якындагы территорияне яшелләндерергә вәгъдә бирәм. Агач калдыкларын каты көнкүреш калдыклары полигонына мөстәкыйль чыгарачакмын.

Гаризага түбәндәге сканерланган документлар кушымта итеп бирелә:

1) Шәхесне раслаучы документлар;

2) Вәкил вәкаләтләрен раслаучы документ (әгәр гариза бирүче исеменнән вәкил эш итсә);

3) Якындагы корылмаларга яки киселергә тиешле яшел үсентеләр төшерелгән башка юнәлешләргә кадәр кишәрлекнең схемасы;

4) Әгәр җир кишәрлеге күчемсез мөлкәткә һәм аның белән алыш-бирешләргә хокукларның Бердәм дәүләт реестрында теркәлмәгән булса, җир кишәрлегенә хокук билгеләүче һәм хокук раслаучы документларның таныкланган күчермәләре;

5) Биналар һәм корылмалар төзелеше габаритларына эләгә торган яшел үсентеләр киселгән очракта, расланган проект документлары;

6) Агачларны кисү һәм күчереп утырту шартлары территорияләренә кагылучы хуҗалар белән килештерү;

7) Үсентеләрне утыртканда яки күчереп утыртканда, инженерлык челтәрләре вәкилләре белән җир эшләрен үткәрүгә ордер ачу белән килешү төзү.

Сораганда сканерланган документларның төп нөсхәләрен бирергә вәгъдә бирәм.

(дата) (имза) (ФИО)

2 нче кушымта
Агачларны һәм куаклыкларны кисүгә,
ябалдашларын кыскартуга яки
утыртуга рөхсәт бирү буенча
муниципаль хезмәт күрсәтү
Административ регламентына

Агачларны һәм куаклыкларны кисүгә, ябалдашларын кыскартуга һәм утыртуга
РӨХСӘТ

№___ "___" __________ 201_ ел

Гариза нигезендә ________________________________________
____________________________________________________________________
_____
201__ нче елның "__" _______дәге яшел үсентеләрне тикшерү акты һәм 201__ елның "__" ________ хисап исемлеге нигезендә
РӨХСӘТ ИТЕЛӘ:
___________________________________________________________________
((Ф. И. О./гариза исеме)
___________________________________________________________________
(эш төре, эшләрне башкару ысулы)
______________________________________________________________
(адрес)
кисәргә: агачлар _____________________________________________данә
куаклар _____________________________________________________данә
кыскартырга: агачлар ________________________________________ данә
куаклар____________________________________________________ данә
утыртырга: гачлар___________________________________________данә
куаклар_____________________________________________________данә
сакларга: агачлар____________________________________________данә
куаклар ____________________________________________________ данә үлән капламын, туфракның уңдырышлы катламын торгызу _________кв. м
Киселгән агачларны _______көн дәвамында чыгарырга.
Киселгән калдыкларны контейнер мәйданчыкларына ташлау һәм яндыру тыела.
Компенсация формасы: ____________________________________________________
Кисүгә рөхсәтнең гамәлдә булу срогы: ______________________________

Срокка кадәр озайтылды :____________________________ (_________________)
М.у. Ф.И.О., имза, дата

Агачларны сүтү куркынычсызлык техникасы нигезендә башкарыла. Әгәр Россия Федерациясендә гамәлдә булган кагыйдәләр (таләпләр, техник шартлар) нигезендә аерым агач яки куаклыклар (билгеләнгән территорияләрдән агач яки куаклар) киселгән очракта махсус оешмалар (белгечләр) яки махсус җиһазлар җәлеп итеп гамәлгә ашырыла икән, гариза бирүче әлеге таләпләрнең үтәлешен тәэмин итәргә тиеш.

Агачларны һәм куаклыкларны кисү эшләрен башкарганнан соң территорияне гомуми төзекләндерү буенча чараларны гамәлгә ашыру (агач кәүсәләрен, ботакларны, башка чүп-чар чыгаруны да кертеп) мәҗбүри булып тора.

Башкарма комитет Җитәкчесе

Рөхсәт алды: ______________________________________________________

(Ф.И.О., имза, дата)

Рөхсәт ябылды: ______________________________________________________

(Ф.И.О. имза, дата)

3 нче кушымта
Агачларны һәм куаклыкларны кисүгә,
ябалдашларын кыскартуга яки
утыртуга рөхсәт бирү буенча
муниципаль хезмәт күрсәтү
Административ регламентына

Яшел үсентеләрне тикшерү

АКТЫ № _______________

Түбәндәге составта: Комиссия рәисе (вазыйфа, ФИО) _____________________

Комиссия әгъзалары (вазыйфа, ФИО)_________________________________

______________________________________________ произведено

табигать һәйкәле территориясендә (объектның исеме) яшел үсентеләр тикшерелде. Бу территориядә түбәндәге үсентеләргә (санитар кисүләр, кыскартулар, кисүләр) кирәк дип билгеләнде:

| №т/б | Исеме | Диаметр (см) | Торыш тасвирламасы |
|---|---|---|---|

Комиссия рәисе:

Комиссия әгъзалары:

Кушымта
201__ елның “__”_______№____
яшел үсентеләрне тикшерү актына

Бетерелергә тиешле агачлар һәм куаклыкларның хисаплау кәгазе.

(агач исеме) данә
(агач исеме) данә
(агач исеме) данә
(агач исеме) данә
(агач исеме) данә
(агач исеме) данә
Комиссия рәисе: Башкарма комитеты Җитәкчесе
Комиссия әгъзалары: Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары
Башлык урынбасары
Белгеч

4 нче кушымта
Агачларны һәм куаклыкларны кисүгә,
ябалдашларын кыскартуга яки
утыртуга рөхсәт бирү буенча
муниципаль хезмәт күрсәтү
Административ регламентына

Татарстан Республикасы
______________муниципаль районы
Башкарма комитеты
Җитәкчесенә
__________________________нан

Техник хатаны төзәтү турында
гариза

Муниципаль хезмәт күрсәткәндә җибәрелгән хата турында хәбәр итәм ______________________________________________________________________

(хезмәт күрсәтү исеме)
Язылган:______________________________________________________________________

Дөрес мәгълүматлар:____________________________________________________

______________________________________________________________________

Җибәрелгән техник хатаны төзәтүегезне һәм муниципаль хезмәт нәтиҗәсе булган документка тиешле үзгәрешләр кертүегезне сорыйм.

Түбәндәге документларны терким:

1.

2.

3.

Техник хаталарны төзәтү турында гаризаны кире кагу турында карар кабул ителгән очракта, мондый карарны җибәрүегезне сорыйм:

электрон документны җибәрү адресы E-mail:__________________________;

расланган күчермә рәвешендә кәгазьдә почта аша түбәндәге адрес буенча: ____________________________________________________________________________.

Шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә (җыю, системалаштыру, туплау, саклау, аныклау (яңарту, үзгәртү), куллану, тарату (шул исәптән тапшыру), шәхси үзенчәлекләрне бетерү, блокадалау, шәхси мәгълүматларны юк итү, шулай ук муниципаль хезмәт күрсәтү кысаларында шәхси мәгълүматларны эшкәртү өчен

кирәкле бүтән гамәлләр кабул итүне дә кертеп) үз ризалыгымны, мин тәкъдим итә торган затның ризалыгын раслыйм, шул исәптән автоматлаштыру режимында, муниципаль хезмәт күрсәтү максатларында муниципаль хезмәт күрсәтүче орган тарафыннан карарлар кабул итүне дә кертеп.


Раслыйм: гаризага кертелгән минем шәхесемә һәм мин тәкъдим иткән затка кагылышлы, шулай ук минем тарафтан түбәндә кертелгән мәгълүматлар дөрес. Гаризага кушып бирелгән документлар (документларның күчермәләре) Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән таләпләргә туры килә, гариза биргән вакытта бу документлар гамәлдә һәм анда дөрес мәгълүматлар кертелгән.

Телефон аша бирелгән муниципаль хезмәтләрнең сыйфатын бәяләү буенча сораштыруда катнашырга үземнең ризалыгымны бирәм: ________________________.
______________ _________________ ( ________________)

(дата) (имза) (Ф.И.О.)

5 нче кушымта

## Муниципаль хезмәт күрсәтү буенча гамәлләр эзлеклелеге блок-схемасы



6 нчы кушымта
Агачларны һәм куаклыкларны кисүгә,
ябалдашларын кыскартуга яки
утыртуга рөхсәт бирү буенча
муниципаль хезмәт күрсәтү
Административ регламентына

Еракта урнашкан эш урыннары исемлеге һәм документларны кабул итү графигы

| № т/б | Еракта урнашкан эш урынының урнашкан урыны | Хезмәт күрсәтелә торган торак пунктлар | Документларны кабул итү графигы |
|---|---|---|---|
| 1 | Биектау авылы Полковая урамы, 9 йорт | Биектау районы | Дүш-Җом - 8:00-17:00<br>Шим – 8:00-13:00<br>Сиш –14:00-17:00 (консультация) |
| | | | |
| | | | |
| | | | |

Кушымта
(белешмә өчен)

Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен җаваплы һәм аны башкаруны контрольдә тотуны тормышка ашыручы вазыйфа затларның реквизитлары

Биектау муниципаль районы Суыксуавыл җирлеге Башкарма комитеты

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Башкарма комитет җитәкчесе | ( 884365) 62-8-47 | Bbit.Vsg@tatar.ru |
| Сәркатиб | ( 884365) 62-8-47 | Bbit.Vsg@tatar.ru |

Муниципаль хезмәт күрсәтүне контрольдә тотучы вазыйфаи затларның реквизитлары

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Җирлек Башлыгы | ( 884365) 62-8-47 | Bbit.Vsg@tatar.ru |